**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пунктында гражданнарның үзара салымын
кертү турында

25.03.2024 ел № 3

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 14 мартындагы «2024 елның 25 мартындагы "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы, 2024 елның 25 мартындагы "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 3 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында»гы 3 санлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «2024 елның 25 мартындагы "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 3 санлы, 2024 елның 25 мартындагы "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегенең Ык торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 3 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Ык торак пунктының Яшел урамы буенча торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юллар төзү, смета буенча: вак таш сатып алу, нигез әзерләү, ташу, салу, проект-смета документациясен әзерләү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) Ык торак пунктында торак пункт чикләрендәге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирлек эчендәге юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)?»

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Димтамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (реер//pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Л.М.Хәйруллина